ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ.......................................................................................................3

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. Татар теленеӊ фразеологик системасы
1.1. Фразеологиянеӊ өйрәнү этаплары.....................................................................5
1.2.Фразеология системасы бүгенге татар телендә..............................................6
ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. Котбныӊ «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында фразеологизмнар.
2.1 Алтын Урда чоры әдәбиятыныӊ вәкиле - Котб...........................................11
2.2.”Хөсрәү вә Ширин” поэмасында фразеологизмнар бирелеше..................17

ЙОМГАК.......................................................................................................24
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ...........................................................................26

# КЕРЕШ

Һәр халык үзенең культурасын, сәнгатен тудыра, бөтен дөнья культурасына кушылып, аны тулыландыра, баета, тагын да үстерә. Борынгы гасыр караңгылыгында җәүһәр булып ялтыраучы, янар йолдыз булып балкучы шәхесләр, фикер ияләре әдәбиятны үстерү өчен һәрдаим көрәш алып барганнар. Котб, Сәгъди, Кол Гали, С.Сараи кебек талантлы әдип һәм шагыйрьләр бу көрәшкә искиткеч зур өлеш керткәннәр. Минемчә, нәкъ шушы шәхесләрнең тырышлыгы, көчле омтылышы безнең татар әдәбиятын югарыга күтәргәндер, бүгенге көн дәрәҗәсенә җиткергәндер. Бу шәхесләрнең кыю фикерләре, бай иҗат хәзинәләре дөньякүләм әдәбиятта да зур урын биләп, үзләреннән соң килгән буыннарга рухи азык, илһам биреп торалар.

Шәрыкның даһи акыл ияләре һәм шагыйрьләре иҗат иткән әсәрләрне татар халкы борын заманда да, соңрак та яратып укый. Бигрәк тә фарсы әдәбияты йогынтысында Алтын Урданың үз шагыйрьләре, әдипләре күренә башлый. Урта гасырлардан татар әдәбияты үрнәкләре дип бүген без Сәйф Сараиның “Гөлстан бит-төрки”, Котбның “Хөсрәү вә Ширин”, Харәзминең “Мәхәббәтнамә”, Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” поэмаларын, Насретдин Рабгузыйның “Кыйссасел-әнбия” (“Пәйгамбәрләр тарихы”) һәм дә Мәхмүд бине Галинең “Нәһҗел-Фәрадис” (“Оҗмахларның ачык юлы”) дигән чәчмә әсәрләрен күрсәтеп китә алабыз.

Котб — Алтын Урда җирлегенең һәм чорының күренекле вәкиле. “Хөсрәү вә Ширин” авторы мәхәббәтне җәмгыятьнең юлдашы, кешелек яшәешенең асылы дип саный. Әйе, моннан җиде гасырлар элегрәк якты дөньяга килгән Котб хаклы, мәхәббәт кенә кешене яшәтә, гаделлеккә, инсаниятkә корылган мәхәббәт кенә җәмгыятьне үстерә.

Бу хезмәт Котб әсәрен тикшерүгә багышланган, ягъни әдип кулланган тотрыклы сүзтезмәләрне табу. Китерелгән хезмәтнең әйтелгән темасы төп максаты булып тора. Төп максатка ирешү өчен безнең тарафытан түбәндәге мәсьәләләр хәл ителде:

- Котбның тормыш һәм иҗат юлы өйрәнелде;
- Әдипнең иҗат үзенчәлеге тикшерелде;
- “Хөсрәү вә Ширин” әсәре укылды һәм өйрәнелде.

Шулай ук чыганаклардан берсе буларак поляк галиме А.Зайончковскийның 1958нче елда чыккан әсәрнең транскрипциясе алынды.

Хезмәт керештән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгактан һәм әдәбият исемлегеннән тора. Кереш бүлегендә теманың төп максаты һәм мәсьәләләре ачыкланып килә. Беренче бүлектә фразеологиянең өйрәнү этаплары тикшерелде. Икенче бүлек әдипнең иҗат юлы һәм “Хөсрәү вә Ширин” поэмасына багышланган. Әсәрнең лексикасы өйрәнелгән. Йомгаклауда хезмәтнең төп нәтиҗәләре билгеләнгән.

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. Татар телендә фразеологик системасы

## 1.1. Фразеологиянең өйрәнү этаплары

Мөстәкыйль фән өлкәсе буларак фразеология XX гасырның 40 нчы елларында гына барлыкка килә. Аның өйрәнүенә А.А.Потебня, И.И.Срезневский, А.А.Шахматов һәм Ф.Ф.Фортунатов хезмәтләре багышланган. Фразеологиягә карата тирән теоретик карашлар 50 нче елларда гына барлыкка килә. Бу очракта Ш.Балли, В.В.Виноградов хезмәтләрен искә төшерергә мөмкин. 60-80 нче елларда фразеология теориясенә рус һәм гомуми тел белеменә О.С.Ахманова, Н.М.Шанский, А.М.Бабкин кебек галимнәр зур өлеш кертәләр. Фразеологиягә карата шулай ук Шарль Балли хезмәтләре турында әйтеп китәргә кирәк. Ул фразеологик әйләнмәләрне гадәттәге сүз тезмәсе, фразеологик төркем һәм фразеологик бөтен дигән төрләргә бүлә. Аерым сүзләре үзләренең мөстәкыйльлеген әле чагыштырмача саклап калган тезмәләрне фразеологик төркем дип, ә аерым кисәкләренең мөстәкыйльлеге тулысынча югалган тезмәләрне фразеологик бөтен дип атый. В.В.Виноградов исә фразеологик бөтеннең үзен икегә бүлә: фразеологик ныгыма һәм фразеологик бөтен. Фразеологик ныгыманың мәгънәсе, ди ул, аны төзүче кисәкләрнең мәгънәсенә һич тә туры килми. Фразеологик бөтеннең мәгънәсен исә аны төзүче кисәкләрнең мәгънәсеннән чыгып ничек тә аңлатып була. Н.М.Шанский фразеологик әйләнмәләрнең бу өч төре эченнән тагын бер төркемне - фразеологик әйтелмәләрне аерып чыгара.[1]

Бүгенге фразеологиядә аңа карата ике карашны билгеләргә мөмкин. Беренчесе – киң караш. Икенче караштa исә фразеологиягә тулысынча һәм махсус үзләштерелгән сүзтезмәләр генә кертелә. Аларның эчендә сүзләргә

---

[1] Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 114 б.

башка мәгънәләр бирелә, алар образлы рәвештә яңача аңлашылалар. Беренче карашны О.С.Ахманова кебек галимнәр яклап чыга. Икенче карашны аерым гына галимнәр. Әйтик, шул ук хезмәттә В.П.Жуков фикере китерелгән. Икенче караштa фразеологик берәмлекләр саны этимологик яктан гына таркала торган сүзтезмәләр кертелгәне аңлашыла. Бу өлкәдә безнең хезмәтебезгә карата Н.М.Шанский позициясе якынрак. Нәкъ аның бигеләмәсе күп төрле энциклопедияләргә кертелгән.

## 1.2. Фразеология системасы бүгенге татар телендә

Татар теленең фразеологик фонды бай һәм күпкырлы. Ул кеше сөйләмен баетуда, үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә художестволы әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуды әһәмиятле роль уйный. Фразеологиядән оста файдалана белү - язучы-художник әсәренең уңышлы һәм отышлы ягы: автор образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә. Танылган татар лексика белгече һәм лексика буенча әсбаплар авторы Г.Х.Әхәтов бөтен фразеологик әйтелмәләрне берничә төргә төркемли:[1] “Татар телендәге фразеологик әйтелмәләрне ике төркемгә бүләргә мөмкин: 1) идиомалар, 2) фразеологик тезмәләр”. Идиомага Г.Х.Әхәтов түбәндәге аңлатма бирә: “... нинди дә булса бер телгә хас булган һәм икенче телгә сүзгә-сүз тәрҗемә ителми торган сөйләм әйләнмәсе; үткен, төгәл, сәнгатьле әйтем, сөйләм”, ягъни структураларын үзгәртмичә саклый һәм күчерелмә мәгънәдә генә кулланыла торган фразеологик әйтелмәләр идиома дип атала. Идиомаларны тагын ике төркемгә бүлеп була: факультатив идиомалар һәм даими идиомалар. Нинди дә булса идиома контекстка бәйле булса, аны факультатив идиома дип

[1] Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма) / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1995. – 54 б.

атыйлар. Мәсәлән, *“эреп төште”* сүзтезмәсе очраклы гына идиома була ала, чөнки ул үзенең туры мәгънәсендә дә еш очрый: Түбәдән боз эреп төште. Икенче төр идиомалар контекстка бәйле түгел. Алар теләсә кайсы контекстта идиома булып торалар: *кылны кырыкка яру, арага кыл сыймау, арт сабагын укыту, түбәсе күккә тию, күлен күккә очыру, баш вату.* Фразеологик тезмәләрне шулай ук ике төркемгә бүләргә мөмкин: фразеологик штамплар һәм фразеологик берәмлекләр. “Фразеологизм штамплар, башлыча, сөйләүченең сөйләмгә төрлечә мөнәсәбәтен чагылдыралар: *шуның белән бергә (вместе с тем), бер-бер артлы (один за другим), озын сүзнең кыскасы (короче говоря) һ.б.*”. Фразеологик берәмлекләрнең кулланышы чикләнгән була. Г.Х. Әхәтов фикере буенча, “алар гадәттә башта кулланылган контекстыннан аерылып, үз алдына мөстәкыйль рәвештә күп куллану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аларны гадәттә бер телдән икенче телгә тәрҗемә итеп булмый. Мәсәлән, *ай тотылу, күңел болгану, эч пошу, йөрәк яну, таң ату...*”. Аерым Г.Х. Әхәтов шулай ук фразеологик терминнар һәм фразеологик атамаларны билгеләп үтә. Аның фикеренчә, “фразеологик терминнарга яки фразеологик атамаларга, башлыча, иҗтимагый-политик һәм социаль-экономик характердагы терминнар керә: *халыклар дуслыгы, совет патриотизмы, Югары Совет, Фәннәр Академиясе, Америка Кушма Штатлары һ.б.”* [1]

Үзебезнең хезмәтебездә без бөтен фразеологик әйтелмәләрне дүрт төргә бүлеп карадык: фразеологик ныгымалар, фразеологик бөтеннәр, фразеологик тезмәләр һәм фразеологик әйләнмәләр. Кыскача, аларга түбәндәге аңлатмалар биреп була: фразеологик ныгыма эчендәге сүзләрнең кайчандыр туры мәгънәдәме, күчерелмә мәгънәдәме кулланылган бары тик этимологик тикшеренү юлы белән генә ачыкларга яки чама белән генә күз алдына китерергә мөмкин. Фразеологик ныгыма эчендәге кисәкләрне бер-

[1]Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма) / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1995. – 58 б.

берсеннән аерып та, аларның кайсын да булса берсен синоним сүз белән алыштырып яки араларына берәр сүз кыстырып та булмый. Фразеологик ныгыманың мәгънә бөтенлеге аның эченә кергән сүзләрнең, морфологик формаларның үзара тыгыз бәйләнеше, шулай ук анда кайвакыт бүгенге көндә инде аңлашылмый торган сүзләрнең һәм катып калган синтаксик бәйләнешнең булуы аркасында саклана. Мисаллар: *җик күрү, ләчтит сату, тел бистәсе.* Фразеологик бөтеннең нигезендә күчерелмә мәгънә ята: аны төзүче кисәкләрнең үз мәгънәләренә карап, теге яки бу күренешнең ни өчен шулай дип аталганын аңлау әллә ни читен түгел. Аның фразеологик ныгымадан аермасы шунда: анда образлылык ярылып яту өстенә, ул форма ягыннан да бөтенләй үк катып калган түгел: фразеологик бөтен эчендәге сүз-кисәкләрне, сөйләмнең таләбенә карап, бер-берсеннән аерырга яки соңгы кисәкне генә түгел, баштан яки уртадагы кисәкне дә грамматик яктан үзгәртергә мөмкин. Мәсәлән: *көймәсе комга терәлгән; кулы арасына керә башлады – кул араңа керә башлаган иде.* Сан ягыннан фразеологик бөтен фразеологик ныгымага караганда күбрәк, әлбәттә. Һәм аларның бик күбесе рифмага яки махсус ритмикага нигезләнә *(ай күрде, кояш алды; ике исәп - бер хисап һ.б.)*. Фразеологик тезмә бары тик шул әйләнмәдә генә кулланыла торган сүз белән башка очракларда кулланыла ала торган сүзнең үзара бәйләнеше рәвешендә ясала. Мәсәлән, *йөзтүбән ята* дигәндә йөзтүбән сүзе яту яки төшү сүзе белән генә килә ала. Башка сүзләр белән ул бәйләнешкә керми. Ята сүзе исә башка очракларда да кулланыла *(җирдә таш ята; чирәмдә бозау ята һ.б.)*; *тузга язмаган* сүз дигәндә дә тузга язмаган әйтелмәсе бары тик сүз белән генә бергә йөри. Фразеологик әйтелмә ирекле кулланыштагы сүзләрдән ясала. Моның гадәттәге сүз тезмәсеннән аермасы шунда, ул сөйләм барышында гына, вакытлыча гына тумый, ә кирәк вакытта тел хәзинәсеннән әзер килеш алына. Моңа төзүче кисәкләре башлыча туры мәгънәдә кулланылган һәртөрле атамалар һәм берәр төрле фикерне белдерүдә калыплашкан, гадәткә кереп киткән әзер әйтелмәләр керә. Мисаллар: *югары уку йорты, мәгариф министрлыгы, эш хакы.* Фразеологик

әйләнмәләр грамматик төзелеше ягыннан ике төрле булалар: җөмлә рәвешендә һәм сүз тезмәсе рәвешендә. Җөмлә рәвешендә фразеологик әйләнмәләргә гомум халык телендәге мәкальләр, язма әдәбияттагы канатлы сүзләр (хикмәтле сүзләр) керә: *Кысканга былтыр, кычкыраларммы быел* (Г.Тукай); *Аюдан курыккан урманга бармас.* Сөйләшү стиленең кайбер калыплашкан фразеологик әйләнмәләр дә төзелеше белән аерым җөмлә тәшкил итә: *Сау булыгыз.*Сүз тезмәсе рәвешендәге фразеологик әйләнмәләр гомум халык телендәге әйтемнәр һәм һәртөрле тотрыклы сүз тезмәләре керә. Мисаллар: *бүрекле карга, хәйләкәр төлке, сабан туе, урта мәктәп.*
Стилистик кулланышы ягыннан бөтен фразеологик берәмлекләрне түбәндәгеләргә бүлеп була:

1) стилистик битараф фразеологик әйләнмәләр;
2) сөйләшү стиленең фразеологик әйләнмәләре;
3) халык авыз иҗаты фразеологик әйләнмәләре;
4) язма сөйләм фразеологик әйләнмәләре.

Стилистик битараф фразеологик әйләнмәләр һәр төр сөйләмдә кулланыла. Алар чынбарлык күренешләрен теге яки бу яктан бәяләмиләр, нинди дә булса тойгы яки тәэсир итү көче белән дә сугарылмыйлар, бары тик билгеле бер төшенчәгә гади бер атама гына булып киләләр. Мәсәлән: *урак өсте, алма бакчасы, ял көне.* Стилистик битараф фразеологиягә, кагыйдә буларак, фразеологик әйтелмәләр керә. Сөйләшү стиле фразеологик әйләнмәләрнең күпчелеге (аеруча, мәкаль һәм әйтемнәр) өчен образлылык хак. Алар сөйләмгә гадилек, яратып яки ачулынып әйтү, мыскыллау яки шаярту төсмере һәм башка шундый тәэсирле яңгыраш бирәләр. Халык теленең үткен, сурәтле сүз чарасы буларак матур әдәбиятта да яратып кулланылалар. Әйтик: *коры куык, тукран тәүбәсе.*[1]

---

[1] Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 116 б.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында фразеологизмнар.

## 2.1 Алтын Урда чоры әдәбиятының вәкиле - Котб

Алтын Урда рухи мәдәниятенең нигезен бу дәүләт барлыкка килгәнче булган ике этномәдәни дөнья тәшкил иткән. Аның берсе - җирле төрки, башлыча, кыпчак дөньясы булып, икенчесе - Үзәк Азиядән килгән төрки-татарлар һәм беркадәр, бигрәк тә Алтын Урда тарихының башлангыч чорында, монголлар санала. Үзәк Азиядә яшәгән төркиләрнең, шул исәптән борынгы татарларның һәм аларның көнбатыштагы кардәш күршеләре булган кыпчакларның да рухи дөньясы барыннан да бигрәк таштан ясалган кеше сурәтләрендә сакланып калган. Монголиядә, Алтайда, шул тирәдәге башка төбәкләрдә VI—VII йөзләрдә куелган таш сыннар дошман явында һәлак булган сугышчы образын гәүдәләндерә. Аның өстендә хәрби кием, бер кулына ул кылыч, икенчесенә касә тоткан. Мәҗүси төркиләр шуның янына килеп, үзләренең йолаларын уздыра торган булганнар. Бер кулына касә тоткан таш сын гүя шунда үзе дә катнаша.

Көнбатыштарак яшәгән тугандаш кыпчак халкында балбаллар азмы-күпме аерылып тора: аларда кешеләргә охшашлык күбрәк, таштан ара-тирә хатын-кыз сынын да ясап куялар (русларның “каменная баба” дигәне шуннан чыккан булса кирәк). Кыпчак балбаллары савытны ике куллап корсак турысында тоткан. Мөгаен, ул савыт, җан ияләрен теге дөньяда рәхәт мул тормыш көтә, дигәнне аңлатадыр. Балбалларны өйрәнүче галимнәр фикеренчә, кыпчаклар шул рәвешле үзләренең борынгы бабаларын илаһи бер батыр зат итеп күргәннәр. Алай табыну сыйнфый җәмгыятькә кадәр, кабиләләр булып яшәгән заманнарда кабилә башлыкларын олылаудан килә. Монголлар яу белән киләләр дә, ул башлыкларның кайсыларын читкә тибәреп, кайсыларын үтереп, алар урынын үзләре алалар. Алтын Урда

дәүләте төзелгәч, Дәшти Кыпчак далаларында балбал куюдан туктыйлар. Моңа, әлбәттә, адәм сын ясауны һәм шуңа табынуны тыйган ислам диненең дә йогынтысы булмый калмаган.

Икенче яктан караганда, ислам дине кабул итү шәһәрләрнең үсеп китүенә, рухи дөньяның көчәюенә, гарәп алфавитының керүенә, язма китапларның киң таралуына сәбәпче була. Җучи улусында фарсы һәм гарәп дөньясының X йөз даһи шагыйрьләре Фирдәүси белән Рудаки, XI йөзнең бөек шагыйрьләре әл-Мәгарри белән Гомәр Хәйям, XII йөзнең суфи шагыйре Гаттар белән Низами, XIII йөзнең Руми белән Сәгъди һәм Шәрыкта иҗат иткән бүтән шагыйрьләрнең мәшһүр әсәрләре киң таралган була. Фирдәүсинең үлмәс “Шаһнамә” поэмасыннан алып Сәгъдинең “Гөлстан”ына чаклы ул әсәрләр һәммәсе дә фарсы телендә язылып, фәкать гарәп шигъриятенең классигы әл-Мәгарри китаплары гына гарәп телендә була.[1]

Шәрыкның даһи акыл ияләре һәм шагыйрьләре иҗат иткән әсәрләрне татар халкы борын заманда да, соңрак та яратып укый. Бигрәк тә фарсы әдәбияты йогынтысында Алтын Урданың үз шагыйрьләре, әдипләре күренә башлый. Урта гасырлардан татар әдәбияты үрнәкләре дип бүген без Сәйф Сараиның “Гөлстан бит-төрки”, Котбның “Хөсрәү вә Ширин”, Харәзминең “Мәхәббәтнамә”, Хисам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан” поэмаларын, Насретдин Рабгузыйның “Кыйссасел-әнбия” (“Пәйгамбәрләр тарихы”) һәм дә Мәхмүд бине Галинең “Нәһҗел-Фәрадис” (“Оҗмахларның ачык юлы”) дигән чәчмә әсәрләрен күрсәтеп китә алабыз.

Боларның байтагысы фарсыдан тәрҗемә генә булып күренүе бик ихтимал. Бигрәк тә инде Котб “Хөсрәү вә Ширин”не Низами Ганҗәвидән, Сәйф Сараи “Гөлстан”ны Сәгъди Ширазидан алып язган, хәтта исемнәрен дә үзгәртмәгән, дип уйларга урын бар. Әмма Алтын Урданың талантлы шагыйрьләре фарсы классикларының поэмаларын турыдан-туры безнең телгә

---

[1] Амирханов Р.М. От Кутба до Сайфа Сараи / Амирханов Р.М // Татарская социально-философская мысль средневековья. – Казань: Таткнигосиздат, 1993. – 57 с.

тәрҗемә итү белән канәгатьләнмичә, аларга иҗади килеп, урта гасырлардагы татар-кыпчак дөньясының, кала һәм дала халкының рухын-көнкүрешен чагылдыралар. Әдәбият галимнәре фикеренчә, борынгы заманнарда һәм урта гасырларда, гомумән язучылар мәгълүм сюжетларны оста файдаланалар. Бу күренешне үз чорының шигъри кануны, дөньяны кабул итүнең һәм шигъри фәлсәфәнең эстетик калыбы итеп санарга кирәк. Шул гадәтне шагыйрьләр соңга таба да бөтенләй үк онытып бетермиләр. Пушкин белән Тукай, мәсәлән, йә берәр даһига ияреп, йә берәрсенең әсәренә көлеп, пародия төсендә өр яңа әсәрләр иҗат итүләре белән дә шигъриятькә үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Котб үзенең “Хөсрәү вә Ширин” әсәрен Сарай (Сарай-Бәркә) шәһәрендә 1342 елда тәмамлаган. Хөсрәү—тарихи шәхес: 590— 627 елларда Фарсы мәмләкәтенең шаһы була (тарихи чыганакларда—Хосрой II, Хосрой Парвиз); атаклы шаһ Хосрой Анушированның (Хосрой I) оныгы һәм аның әбисе Төрки каханлыгын төзүчеләрнең берсе, инде безгә таныш Истәми каханның кызы була. Хөсрәү белән аның хатыны Ширинның кичергәннәре Фирдәүсинең “Шаһнамә”сендә дә, бүтән шагыйрьләр иҗатында да тасвирлана. Фарсы поэзиясендә нык таралган темага кызыгып, 1181 елда Низами да һәм менә 1342 елны Котб та поэма иҗат итәләр.[1]

Котб әсәренең үзәгендә Хөсрәү белән Ширинның мәхәббәте сурәтләнә. Әмма Ширинга япь-яшь, гаҗәеп көчле, рәссам булу өстенә янә йөз һөнәр иясе Фәрһад та гашыйк. Аның гыйшкын автор намуслы затның илаһи саф хисе итеп тасвирлый. Каһарманнарының килеш-килбәтләрен сурәтләгәндә дә, изге хисләренә үз бәясен биргәндә дә автор һичбер мактау сүзен кызганмый:[2]

*...Гъишык берлә терек ошбу галәм! —*

[1] Наджип Э.Н. “Хосрау и Ширин” Кутба и его язык: Тюркологический сборник / Э.Н. Наджип. – Москва: Наука, 1966. – 109 с.

[2] Әхмәтьянов Р. “Хөсрәү вә Ширин” / Р. Әхмәтьянов // Мирас. – 1992. - №2. – 22 б.

*Әгәр гъишык булмаса, булмас ирде адәм.*

Поэманың башыннан алып ахырына кадәр хатын-кызга ихтирам чагыла. Гомумән алганда, бөтен Шәрыктагы кебек үк, Алтын Урдада асыл затны олылау гадәте яши. Бу уңайдан Ибне Баттута: “Бу якларда хатын-кызга карата аларның (татарларның) олуг хормәт күрсәтүенә шаклар каттым. Ир-ат белән чагыштыргысыз зур хөрмәт үзләренә”,[1] - дип яза.

Котбның тезмә юллары замандашларына да (Харәзмигә), аннан соң әдәбиятка килгән шагыйрьләргә дә: Мөхәммәдьярга (XVI йөз), Утыз Имәнигә (XVIII-XIX йөзләр), Тукай белән Бабичка (XX йөз башы) нык тәэсир итә.

Профессор Р. Ганиева Алтын Урда чорын татар әдәбиятының Яңарыш чоры дип билгеләп үтә. Бу чорның аеруча күренекле әсәре итеп Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасын күрсәтә. Профессор фикеренчә, бу ядкәр “Алтын Урда чорындагы Яңарыш әдәбияты җәүһәрләренең иң күренеклесе. Яшәү фәлсәфәсен гәүдәләндерү ягыннан да, сәнгатьлелек күзлегеннән караганда да, “Хөсрәү вә Ширин” поэмасында көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең кайберләре бүген дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаган”.[2]

Котб псевдонимы белән “Хөсрәү вә Ширин” поэмасын язган Алтын Урда шагыйре шул дәүләт составына кергән халыкларның әдәбият тарихында күренекле урын тота. Бу әсәр ул замандагы рухи культура һәм әдәбиятның үсеш дәрәҗәсен күрсәтүе, иске әдәби традицияләрне дәвам иттерүе, болгар-татар-ларның һәм Урта Азия халыкларының әдәбияты үсешенә тәэсир итүе ягыннан бик әһәмиятле. Алтын Урда дәүләте составына кергән Харәземдә һәм Болгарда, монголлар килүдән элек гыйлем һәм фән шактый алга киткән булып, күренекле галимнәр яшәгәнлеге мәгълүм. Ул галимнәр бу дәүләттә матди һәм рухи культураны һәм әдәбиятны үстерүдә

[1] Хисамов Н. XIV йөз шигъриятендә кеше идеалы / Н. Хисамов // Казан утлары - 1978. - №3. – 32 б.

[2] Ганиева Р. Алтын Урда чорындагы Яңарыш әдәбияты / Р. Ганиева // Мәгариф. – 1997. - №3. – 27 б.

зур эшчәнлек күрсәткәннәр. Нәтиҗәдә Сарайда, Болгарда һәм Кырымда фән кешеләре, әдипләр, шагыйрьләр җитешкән.

Алтын Урдада төрки телдә әдәбият һәм поэзиянең нык алга киткән булуына Мәхмүд Болгариның “Нәһҗел-фәрадис”е, Котбның “Хөсрәү вә Ширин”е, Харәзминең “Мәхәббәтнамә”се, Хөсам Кятибнең “Җөмҗөмә солтан”ы, Галинең “Кисекбаш китабы”, Сәйф Сарайның “Китабе Гөлстан бит-төрки”се, “Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасы, шигырьләре һәм ул җавап язган шагыйрьләрнең әсәрләре шаһит. Бу авторларның хан сарайларында тәрбияләнгән профессиональ шагыйрьләр булмыйча, халык арасыннан үсеп чыккан сәнгаткярләр булуы аеруча игътибарга лаек. Бу хәл гыйлем һәм мәгърифәтнең хаким сыйныф тирәсендә түгел, халык арасында таралганына дәлил. Алтын Урда, Болгарда һәм башка мөселман илләрендә мәдрәсәләр дәүләт карамагында булмаган, аерым галимнәр мәдрәсә тоткан һәм шул традиция болгар-татарлар арасында да дәвам иткән. Ул мәдрәсәләргә төрле шәһәр һәм авыллардан гыйлемгә ихласлы яшьләр килеп укыганнар, араларыннан зур галим, яхшы шагыйрьләр дә чыккан. Әлбәттә, Сараи дигән галим вә шагыйрьләрнең барысы да Сарайда туып үсмәгән, моны Сәиф Сараиның “туган җирем Камышлы” дигәненнән дә күрәбез. Аның Сарай якынындагы Камышлыдан икәне шиксез.

Болгар һәм Алтын Урда заманында Идел буе галимнәре һәм әдип-шагыйрьләре гарәп, фарсы телләреннән һәм әдәбиятларыннан яхшы мәгълүмат алганнар. Болгар һәм Алтын Урта шагыйрьләренең элекке әдәби традицияләрне дәвам иттерүләре дә кызык. Элек гарәпчә шигырьләр язып, соңыннан шул ук шигырь формаларын фарсычада кулланган һәм гарәпчәдән бик мөһим әсәрләрне фарсычага күчергән фарсы-таҗик шагыйрьләре шикелле, төрки шагыйрьләр дә бөек фарсы шагыйрьләренең әсәрләренә ияреп язу, яки ирекле тәрҗемә итү юлын тотканнар. Йосыф Хас Хаҗиб Баласагуни “Котадгу белег”не Фирдәүсинең “Шаһнамә”сенә ияреп, аның вәзенендә язган. Алтын Урда мәҗлесләрендә, гарәпчә шигырьләр укыганнан соң, фарсы һәм төрки “мөләммәгъ” җырлаулары да шул ук традицияне

күрсәтә. “Мөләммәгъ” дип бер яки ике юлы гарәпчә, бер-ике юлы фарсыча, яисә фарсыча-төркичә шигырьләргә әйтелә. Низами, Хафиз кебек олуг шагыйрьләр, берьюлы гарәпчә дә, фарсыча да газәл-шигырьләр язганнар. Алтын Урда шагыйрьләренең дә шуларга ияреп фарсыча-төркичә “мөләммәгъ”ләр язуы һәм ул “мөләммәгъ” газәлләрнең мәҗлесләрдә укылуы яки кубыз көенә җырланганы мәгълүм. Мондый “мөләммәгъ” шигырьләрнең бик модада булганын “Хөсрәү вә Ширин” ахырында гарәпчә-фарсыча “мөләммәгъ” китергән Бәркә Фәкыйһ тә күрсәтә. Ул ике юл гарәпчә һәм ике юл фарсыча шигырь белән: “Бу китапны матур язу өчен озак вакыт тырыштым; бердән үлеп китсәм, аны аз нәрсә бәрабәренә, суган бәясенә сатуларыннан куркам”,[1] - дип язган.

Төрки авторлар мәшһүр фарсы шагыйрьләренең әсәрләре белән яхшы таныш булганнар һәм үз әсәрләрен шуларга ияреп иҗат иткәннәр. Котб исә Низаминың “Хөсрәү вә Ширин”ен ирекле тәрҗемә иткән. Төрки вариантта авторның мөстәкыйль иҗат өлеше дә шактый урын ала. Котб үзеннән алда булган төрки әдәбиятлардагы Йосыф Хас Хаҗибнең “Котадгу белег”е, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”ы, Әхмәт Югнәкинең “һибәтел-хәкаик”ы кебек күренекле әсәрләр белән таныш булып, алардан билгеле бер йогынты алса, “Хөсрәү вә Ширин”е белән соңгырак чор шагыйрьләренә үзе дә йогынты ясаган. Бу танышлык һәм тәэсир Низами әсәре нигезендә 1409—1414 елларда “Мәхзәнел-әсрар” поэмасын язган Мир Хәйдәр иҗатында да күренә. Аның Низами темасын сайлауда да Котбка ияргәнлеге сизелеп тора.

Урта гасыр әдәбияты билгеле сюжетлар белән эш итүне өстен күрә. Бу күренеш Алтын Урда чоры әдәбияты өчен дә хас. Әмма шуңа да карамастан, бу төр әсәрләр игътибарны җәлеп итәләр, чөнки авторлар билгеле материалны үзләренчә эшкәртәләр, өстәмә фактлар, шигъри детальләр белән баеталар. Мондый әсәрләргә Хисам Кятибның “Кисекбаш”ын, С. Сараиның

---

[1] Таһирҗанов Г.Т. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәре / Г.Т. Таһирҗанов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.1. - Казан:Татар.кит.нәшр., 1984. – 281 б.

“Хөсрәү вә Ширин”ен алырга була. Алтын Урда әдипләре − реаль тормыш, чынбарлык материалы белән эш итәргә омтылганнар. Котб, мәсәлән, Алтын Урда ханы Тенибәккә багышлап мәдхия яза, Хәрәзмидә Мөхәммәд хуҗа исемле хөкемдар мактала, Әхмәд Үргәнҗинең бер шигырендә Аксак Тимернең явызлыклары фаш ителә, Бәркә Фәкыйһ әсәре автобиографик белешмәләргә бай булуы белән сыйфатлана.

Фән һәм матур әдәбиятның үзара тыгыз бәйләнешен без Алтын Урда чоры язма әдәбиятында да ачык күрәбез. Әмма алар арасында кискен чик юк, алар үзара керешеп китәләр. Мәсәлән, “Нәһҗел-фәрадис” китабын гыйльми һәм эстетик башлангычларның кушылмасы дип атарга мөмкин. Бу чор әсәрләрендә әдәби чаралар ярдәмендә үз дәверенең казанышлары, дөнья турында күзаллаулар чагылыш таба. Мәсәлән, Котб, С. Сараи әсәрләрендә галәм төзелеше, тән һәм җан берлеге, дәүләт идарәсе хакында кызыклы фикерләр бар.[1]

Алтын Урда язма әдәбияты өчен жанрлар төзеклеге, шигъри формаларның һәм чараларның гаҗәеп байлыгы хас. Авторлар сүзләрнең күпмәгънәлелегеннән, сөйләмдәге фонетик һәм синтаксик мөмкинлекләрдән оста файдаланалар. Хикмәтле сүз әйтү традициясе уңышлы дәвам иттерелә. Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Алтын Урда әдәбияты үзенең үсеше, идея-эстетик байлыгы, поэтик байлыгы белән югары дәрәҗәдә торган XIV йөздә ул төрки дөньяның әйдәп баручы үзәгенә әверелгән. Аның традицияләре бүгенге әдәбиятның эстетик үсешендә дәвам итә.

### 2.2. “Хөсрәү вә Ширин” поэмасында фразеологизмнар бирелеше

Аерым галимнәр фикеренчә, “Хөсрәү вә Ширин”дә татар теленең хәзерге Пенза, Мордовия төбәгенә хас шивә (диалект) элементлары ныграк

[1] Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. (Вопросы взаимосвязей и поэтики) / Х. Миннегулов. – Казань: Изд-во КГУ, 1993. – 82 с.

гәүдәләнеш тапкан. Котоба каласы да нәкъ әнә шул җирләргә нисбәт ителә. Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек, “Хөсрәү вә Ширин” авторы да, тәрбияви, әхлакый тормыш тәҗрибәсе бирү ягын күздә тотып, үз әсәрендә кызыклы, тирән фикерле мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр китерә:
*Казгу козгусына төштем, ук нишанга... (мишеньгә) атылыр, җил иссә, яшь үләнгә (“утка”) рәхәт, кипариска кыен булыр, белек берлә күңелдин казгу китәр;*[1] *карын теш ите берлә туймаз һ.б.* Әсәрдәге күп кенә юллар, афоризмдай, мәгънәле яңгырый: *Борынгы зәүкъ һич соңра табылмаз, Карыйлыкда егетлек кыйлса булма. Ничә татлигъ терелсәң (яшәсәң) — ачигъ үлгү (үлем ачы.*[2]

Котб әсәре үзеннән соңгы төрки-татар сүз сәнгате үсешенә зур йогынты ясады. Харәзми, Сәйф Сарай, Мөхәммәдьяр, Әбелмәних Каргалый кебек әдипләр, мәсәлән, гарәп-фарсы әдәби казанышларын үзләштерүдә Котбка хас иҗат принципларын да (тәрҗемә, нәзыйрә, ялгау...) иркен файдаландылар. “Хөсрәү вә Ширин” Алтын Урда әдәби теле үсешендә мөһим роль уйнады. Котб әсәренә хас идея-тематика, сурәтләү һәм тасвир чаралары, шигъри детальләр һәм поэтик фигуралар төрле дәвер татар әдипләре тарафыннан эшкәртелде, иҗади рәвештә кулланылды.[3] “Хөсрәү вә Ширин”дә еш кына *золымдин моңлыны азад кылу, халыкка йар булу, ил күңлен рәнҗетмәү* хакында сүз бара. Бу мотив Сәйф Сарай, Мөхәммәдьяр һәм Тукай әсәрләрендә дә бар. Котб болай ди: “Кеше ни кем кылыр булса кешегә, Килер бер көн һәм ул аның башынга”.[4]

Рифкать Әхмәтьянов — тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор. Ул лексика, тел тарихы, чагыштырмалы лингвистика буенча хезмәтләре белән мәгълүм. Әдәбияттан да хәбәрдар. Ул Котбның “Хөсрәү вә

[1]Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә / Котб. – Казан : КДУ, 1969. - 411 б.

[2] Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман) / Котб. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 187 б.

[3] Миңнегулов Х. Ни белгәйләр сине сүзләтмәсәң тел : Алтын Урда әдәби традицияләре / Х. Миңнегулов // Мирас — 1996. — № 5, 6. - 202 б.

[4] Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә / Котб. – Казан : КДУ, 1969. - 260 б.

Ширин” әсәрен хәзерге телгә тәрҗемә итеп, “Мирас” журналының 1992—1993 елгы саннарында бастырган иде. Тәрҗемә укучылар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан, гомумән, уңай кабул ителде. Аннан аерым өзекләр төрле дәреслек-хрестоматияләргә, әсбапларга да урнаштырылды.

Хәзерге телгә аударылган текст, гомумән, үзбашка әйбәт. Әмма аны оригинал белән чагыштырганда, бәхәсле яклар да туа. Төн нөсхәнең күнчелек сүзләре, сурәтләре, шәкеле бүгенге укучы өчен аңлаешлы. Тәрҗемәче исә, ни сәбәптәндер (әйтерсең тәрҗе-мә әсәре белән түгел, ә башка телдәге текст белән эш итә), иҗади якны көчәйтеп җибәрә: еш кына оригиналдагы таныш сүзләр-не һәм формаларны да яңалары белән алыштыра. Моңа мисаллар бик күп булса да, биредә шуларның бер-икесен генә китерәбез: Гашыйклык берлә шаһлык раст килмәз, Кеше кем гыйшкы юк бу серне белмәз.[1] Р. Әхмәтьянов бу юлларны болай дип тәрҗемә итә: Гашыйклык һәм дә шаһлык төрле-төрле, Гыйшыксыз җан гына белмәс бу серне.

Кыскасы, “Хөсрәү вә Ширин”нең хәзерге телгә тәрҗемәсе, гәрчә фәнни максатларга тулысынча җавап бирмәсә дә, әсәрнең эчтәлеген, идея-эстетик байлыгын бүгенге укучыга ирештерүдә билгеле бер мөһим роль уйный. Журналда басылган текстка Р. Әхмәтьянов аерым өстәмә-төзәтмәләр керткән. Әмма әле тәрҗемәне тагын да камилләштерү сорала. Поэмада тотрыклы сүзтезмәләр киң урын алган, мәсәлән:

дөнья әйләнә - *тормыш дәвам итә. Җир шары; Җир планетасындагы нәрсәләрнең барсы. Чолгап тора торган барлык табигать, тирәлек.*

дөнья күзендә - *җирдә, дөньяви тормышта, дөньялыкта.*

җегәрле ит һушымны - *җегәрле -егәрле / җегәрлек - Нәрсәгә булса да көч-куәт, файда бирү, җитештерү мөмкинлеге / Җегәрлекле - с.Тәэсир көче зур булган; көчле/ Җегәрлелек -Егәрлелек / Җегәрләнү -1.Җегәр, хәл керү, көч җыю, егәрләнү. Гайрәт керү; дәрт, өмет белән бәйле рәвештә көч кереп*

[1] Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә / Котб. – Казан : КДУ, 1969. - 316 б.

*китү, гайрәт арту  2. күч. Җегәрлегә әйләнү, ныгу.*

җиһанга күлмәк  кидерү - *җиһан - дөнья  [нур белән тулды җиһан, ялт итте җир!] / Җиһангир -Дөньяны яулап алып үзенә буйсындыручы, дөньяга хуҗа (кеше, дәүләт турында).*

иҗат утым  *-1.Кешенең рухи, матди байлыклар, культура хәзинәләрен төзүгә юнәлдерелгән мөстәкыйль эшчәнлеге. Шундый эшчәнлек белән бәйләнгән 2.Шул эшчәнлек нәтиҗәсе; берәр кеше яки коллектив тарафыннан барлыкка китерелгән хезмәтнең җыелмасы [халык иҗаты].*

йөзен сөрде - *Кеше башының алгы өлеше, бит. Чырай 2.Ал, ал як [йөзе белән көньякка караган йорт]. Кеше йөзенә, халык йөзенә кебек тезмәләрдә каршысына, алдына мәгънәсендә*

кайгыны оста йоту - *кайгы - 1.Тирән психик кичерешне, рухи газапны; хәсрәтне оста үткәрү, баштан кичерү.*

караш ташлап - к*араш, карап тору рәвеше / Караш -1.Карау юнәлеше яки рәвеше 2.Аң, уй-фикер 3.Чынбарлыкны аңлау, бәяләү.*

көч киселде – *көч -  кемнең яки нәрсәнең булса яшәү сәләте. Нинди дә булса эш башкара торган физик энергия; хезмәт. Энергиянең чыганагы булган матди башлангычы бетү. Авыр, кыен булу [бала ана белән калса анага көч, ата белән калса балага көч]. Көч-бәлә белән - Авырлык белән, көчкә / Көчкә[-көчкә] -1.Эш-хәрәкәтнең, күренешнең бик авырлык белән баруын белдерә 2.Эш-хәрәкәтнең тулы башкарылмавын белдерә / Көч-хәл -Егәр, хәл.*

куаныч чишмәсе - *нәрсәнең дә булса чыганагы, башлангычы, нигезе.*

күзләр нурга тулсын - *ачыклык, ягымлылык, җылылык (күздә, йөздә).*

күңел-җан янды - *берәр эштә фаш ителү, тотылу, авыр хәлдә калу. Әрәм булу, бушка яки файдасызга китү (акча, байлык һ.б-р. турында). Пешкәндәй булу, пешкәндәге кебек ачыту, авырту, сызлау.*

күңлем көзгесен – көзге - *үз алдында булган предметларны чагылдырырлык ялтыравык шома өслек; шундый пыяла. Нинди дә булса күренешнең, процессның чагылышы. Нәрсә дә булса ачыкларга ярдәм итә торган чара.*

рәхмәт орлыгың - *1.Аяу, кичерү, мәрхәмәт [бәлки рәхмәт яңгырыдыр] 2.Яхшылыкка җавап итеп әйтелә торган сүз. Рәхмәт уку - ихлас күңелдән кат-кат рәхмәт әйтү / Рәхмәтле -1.Рәхмәт хисе белдергән.*

сөенеч орлыгын сипте - *1.Сөенү хисе, шатлык 2.Сөенечле, шатлыклы хәбәр. Сөенү – сөендерү - куану, шатлану.*

телеңнең ачкычы - *Нәрсәне дә булса аңлау, чишү өчен чара.*

утны, кайгыны йоту - *Нәрсәгә дә булса дучар булу, шуны баштан кичерү [тау кадәр газап йотып].*

фикер кайнау - *Чынбарлык күренешләренең мидә, аңда чагылышы .Уйлану, фикерләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән уй. Идея. Ният, теләк, план. Аң; дөньяга, чынбарлыкка, тормышка караш [фикер ягыннан үсү]. Берәр өлкәдә белем, танып-белү [фәнни фикер] 5.Берәр нәрсәгә карата булган бәяне белдергән уй, кемгә яки нәрсәгә булган мөнәсәбәт, караш [җәмәгатьчелек фикере]. Рәсми нәтиҗә, карар [суд фикере] 6.Сүздә, сөйләмдә, әдәби әсәрдә һ.б. эчтәлек, әһәмиятле сүз, игътибарга алырдай нәрсә [бер генә яңа фикер дә әйтелмәде]. Фикер алышу - Берәр нәрсә турында үз фикерләреңне,*

*карашларыңны әйтеп, төрле яклап тикшерү, фикер уртаклашу, киңәшләшү. Фикер йөртү -Уйлау, фикерләү. Фикер иясе  - Тирән фикер йөртә белгән галим кеше. Фикер килү  (туу) - Кинәттән нинди дә булса уй килү.*

чәчәкле чәч - *күрер күзгә күркәм; буяуларның, бизәкләрнең, сызыкларның нәфислеге, гармониялелеге белән аерылып торган; чибәр (кешеләр турында). Нәфис яңгырашлы. Теләк-омтылышларны тулы канәгатьләндерә торган; яхшы, күңелле. Хуплана, мактала торган, күркәм. Рухи канәгатьләнү, ләззәт тудыра торган. Сәнгатьле, нәфис.*

Поэмада кулланылган метафораларны да карап үтик:

*Иреннәре ─ Вәдәхшанның якуты* (Губы ─ рубин Вадахшана) (Котб);

*Кояш җиз калканын диңгезгә салды.*

Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасының үзәгендә гүзәл һәм гади рухлы Ширин тора. Аның тешләрен әдип энҗе, алмаз кебек асылташларга тиңли:

*Тигез булып тезелгән теш − нәкъ энҗе,*

*Алар алмаз кебек нурлы, пакь энҗе.*

Кызга һәркем соклана, һәм шул ук вакытта аның сихри гүзәллегеннән күз ояла:

*...Очар җаннар, күбәләктәй, бу шәмгә.*

*Ояла күз, карап булмый гүзәлгә.*

*Кашы җәя аның, ә керфеге − ук,*

*Бу җәй һәм бу ук җирдә бүтән юк...*

Шириннең сафлыгы, намуслылыгы йөз, буй-сын күркәмлеген тагын да тулыландыра:

*Язын аткан чәчәктәй саф, нәфис ул,*

*Аңарга ялгышып та тимәгән кул.*

Мондый пакь, нәзакәтле зат алдында теләсә кем үзен корбан итәргә әзер:

*Кашын күрсә, яңа ай тик мәкелдә,*

*Җанын фида кылыр хәтта хәким дә.*

*...Матурлыкта бу кыз даны җәелгән,*
*Киләләр баш орып аңа күп илдән.*

Котб әсәрендә дә чын мәхәббәтнең олылыгы, кешеләрне рухи яктан баета, үстерә торган көч икәнлеге эстетик яктан гаять тәэсирле итеп бирелә. Шириннең күңел байлыгы, батырлыгы, кыюлыгы, сафлыгы, сөйгәненә тугрылыгы тышкы матурлыгын тагын да арттыра. Тышкы яктан Хөсрәү дә матур, әмма Ширин үзенең сафлыгы, максатка омтылучан булуы белән безнең күз алдыбызда Хөсрәүдән бер башка үсеп китә. Без Шириннең матурлыгына таң калсак, аның, кыюлыгына сокланып туя алмыйбыз, аның бу сыйфатлары алдында баш иябез. Ширин, Фәрһад образлары − тышкы матурлыклары, эш-гамәлләре, рухи сафлыклары миндә соклану хисе уята.

А. Зайончковский әсәре транскрипциясе белән танышу дәвамында без түбәндәге фразеологик ныгытмаларны аерып чагырдык һәм аларның мәгънәсен ачыкладык:

*köz baqsa (көз бакса) — карaса;*

*qanyn tökär (канын түгәр) — сугышыр;*

*ketmäz-sän ögüm-din (китмисең күңелдән) — онытылмыйсың;*

*ojun-ny saldy (уенны салды) — уйнамады;*

*ögindin kitmägäj (уеннан китми) — онытылмый;*

*garib-luq oty ičrä küjsämän (ялгызлык утында көйсәм) — кайгырсам;*

*köŋli birlä nālä vä ah (күңел белән ах ора) — офтана, тирән сулап уфтана;*

*ot-da qalsaŋ (утта калсаң) — кайгырсаң;*

*joluqty žānym (ќаным юлыкты) — очрады;*

*qulaq tut (колак тот) — тыңла;*

*berür žān (ќан бирер) — аның өчен өзелеп торыр, бернәрсә дә кызганмас;*

*qanyny tökmä(каныәны түкмә) — сугышма;*

*qany qajnab(каны кайнап) — ачуланып, ярсып, кызып китеп;*

*žāny učty (ќаны очты) — үлде, вафат булды;*

*alur žan (ќан алыр) — үтерер;*

*žān aldy (ќан алда) — үтерде;*

*közdin sača jaš (күздән яшь чәчү) — елау;*

*čyqүa žany (чыга ќаны) — үлә, вафат була;*

*taŋqa qaldy (таңга калды) — шаккатты, хәйран калды;*

*qany töklür (каны түгелер) — сугышы;*

*žānym aldyŋ (ќаным алдың) — үтердең;*

*qanym qajnady (каным кайнады) — ачуландым, ярсыдым, кызып киттем;*

*erini čäwrülüb kečmiš eŋäkdin (ирене ияккә кадәр төшә) — үпкәләү;*

*baš kötürdi (баш күтәрде) — күтәрелде, көрәшкә чыкты;*

*talyb köŋli qušy (талып күңел кошы) — арып, талчыгып;*

*´aqab-da bolur (харап булыр) — ќимерелер, бетәр;*

*kitmäz äligdin (кулдан китмәү) — куймау;*

*it žānlyү (эт ќанлы) — кешелексез;*

*qyldy mäskän (урын кылды) — урнашты;*

*bašyŋny janur (башың яныр) — үләрсең, бетәрсең, вафат булырсың;*

Әлеге әсәрдән фразеологик берәмлекләргә мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә мөмкин:

*mäŋizi solsa (йөзем сулса) — кайгыдан йөземнең нуры качса, саргайсам;*

*jol tuty (юл тоту) — бер юнәлештә, бер билгеләнгән якка юнәлү;*

*kälür tilgä (телгә килү) — сөйли башлау;*

*tabub jol (юл табып) — тормышта барыр, үсәр-яшәр юлыңны табу;*

*jol urmyš (юл тотты) — бер юнәлештә, бер билгеләнгән якка юнәлү;*

*söz tabšurdy (сүз тапшырды) — әйтелгән сүзне китереп җиткерде;*

*aldy tahtyn (тәхет алды) — баш булды;*

*mihri tösti (мәхәббәте төште) — гашыйк булды;*

*qadүu jut(t)um (кайгы йоттым) — кайгырдым;*

*magzymny qurut(t)uŋ (миемне корыттың, ќелегемне корыттыә) — көчне, малны файдаланып хәлдән тайдырдыә, эшкә яраксыз хәлгә китердең*

*qaraŋγuluq-qa salma (караңгылыкка салма) — билгесезлектә калдырма;*

*sözin saldy (сүзен салды) — үз сүзен әйтте, фикерен белдерде;*

*talyb til (тел талып) — телләр арыганчы сөйләп;*

*tilin tutmaz (телен тотмау) — телен тыймау, кирксә-кирәкмәсә дә сөйләп;*

*sözin qoj (сүзен куй) — сүзен калдыр, аның сүзләрен игътибарга алма;*

*hošlandy köŋli (хушланды күңеле) — хәле яхшырды;*

*tävfiqyŋ qabγyn ača ber (тәүфыйкъ капкасын ачу) — ярдәм итү, булышу;*

*ačty jüzin (йөзен ачты) — үзенең нindiлеген күрсәтте;*

*tabtum köŋül qufly kilidin (күңел йозагына ачкыч табу) — ќаен белү;*

*tyd tiliŋni (телеңне тый) — кирәклесен генә сөйлә, азрак сөйләми тор;*

*`āšyq oty (гыйшык уты) — көчле мәхәббәт хисе;*

*žānynγa ot tutušub (ќанына ут тоташып) — кайгыга калып, кайгырып;*

*adaq astynda saldyŋ (аяк астына салдың) — юк иттең, таптадың;*

*kitär ol közdin ujqu (күздән йокы китү) — йоклый алмау;*

*muŋda tuštum (моңга төштем) — кайгыга калдым, хәсрәтләндем;*

Әлеге төр фразеологик әйтелмәләр поэмада калган ике төргә караганда сирәгрәк очрый. Ләкин шулай да алар әсәрдә үз урыннарын алганнар:

*tilkü-lüg söz (төлке сүзе) — хәйләкәр, мәкерле сүзләр;*

*qadγu otyn (кайгы утын) — күңелне тырнап торучы, тынычлыкны алучы хис;*

*jaman közlüg (яман күз) — кешенең хәлен ќибәрә торган караш;*

*süčüg til (татлы тел) — теле белән күңелгә яраучы, матур, ќылы сүзләр сөйләүче;*

*aγu tilli (агу телле) — усал сүзләр, пычрак сүзләр сөйләүче;*

*temür žān (тимер ќан) — каты, нык бәгырьле, салкын кеше;*

*aj jüzin (ай йөз) — айның нурлылыгын йөзгә күчереп, берсе урынына икенчесен алыштырып әйтү;*

*ädgü atyndyn (изге ат) — изгелек белән телгә алына торган яхшы исем, әүлия дигән исем, мөкатдәс исем;*

*taš köŋül-lüg (таш күңелле) — каты күңелле, каты табигатьле, кеше турында уйламаучы, салкын ќанлы кеше;*

# ЙОМГАК

“Хөсрәү вә Ширин”нең үзәгендә — мәхәббәт. Ул каһарманнарның үзара мөнәсәбәтләре, хис-кичерешләре, эш-гамәлләре, әдипнең фәлсәфи уйланулары, лирик чигенешләре аша төрле яклап ачыла. Автор фикеренчә, чын сөю — инсанилыкның төп асылы. Роман башыннан алып ахырына кадәр эчке бер диалогка, персонажлар, фикер-хисләр арасындагы бәхәскә корылган. Әсәрнең төп, мәгънәви конфликтын мәхәббәткә, яшәешкә, гомумән инсанилыкка карашлар төрлелеге тәшкил итә.

“Хөсрәү вә Ширин”нең мөһим бер үзенчәлеге һәм кыйммәте шунда: биредә мәхәббәтнең инсанны үзгәртергә, рухи яктан камилләштерергә мөмкин булган шифалы көч икәнлеге дә раслана. Шириннең олы мәхәббәте Хөсрәүнең табигатен сафландыра бара, аның мәсләксез тормышына мәгънә кертә, кылган һәм кыласы эш-гамәлләре өчен вөҗдан җаваплылыгын арттыра. Романда мәхәббәт темасының тирән фәлсәфи һәм социаль мәгънәсе ачыла.

“Хөсрәү вә Ширин”дә, мәхәббәт темасына бәйле рәвештә, башка мөһим мәсьәләләр дә гәүдәләнеш тапкан. Шундыйларның берсе - Урта гасырның күн кенә әдипләрен борчыган гадел хөкемдар проблемасы. Әсәрдә эчке мәҗлесләре, шәраб тематикасы, күңел ачу күренешләре шактый зур урын алын тора. Бу берничә сәбән белән аңлатыла. Беренчедән, әсәрдә исламга кадәрге борынгы Иран, Куһистан тормышы сурәтләнә. Мәгълүм ки, Хөсрәү Мөхәммәд пәйгамбәрнең мөрәҗәгатен кире кага. Әсәрдә шаһ гомеренең аянычлы төгәлләнеше билгеле бер дәрәҗәдә шуның белән дә аңлатыла. Икенчедән, мәҗлес, шәраб, җыр, музыка - элеккеге әдәбиятта яшәешне, тулы канлы тереклекне гәүдәләндерү чаралары да. Әмма автор эчеп акыл җуюга, әдәпсез гамәлләр кылуга каршы.

“Хөсрәү вә Ширин”дә татар теленең хәзерге Пенза, Мордовия төбәгенә хас шивә (диалект) элементлары ныграк гәүдәләнеш тапкан. Котоба каласы да нәкъ әнә шул җирләргә нисбәт ителә. Урта гасырның күп кенә әдипләре

кебек, “Хөсрәү вә Ширин” авторы да, тәрбияви, әхлакый тормыш тәҗрибәсе бирү ягын күздә тотып, үз әсәрендә кызыклы, тирән фикерле мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр китерә:

*Казгу козгусына төштем, ук нишанга... (мишеньгә) атылыр, җил иссә, яшь үләнгә (“утка”) рәхәт, кипариска кыен булыр, белек берлә күңелдин казгу китәр;*[1] *карын теш ите берлә туймаз һ.б.* Әсәрдәге күп кенә юллар, афоризмдай, мәгънәле яңгырый: *Борынгы зәүкъ һич соңра табылмаз, Карыйлыкда егетлек кыйлса булма. Ничә татлигъ терелсәң (яшәсәң) — ачигъ үлгү (үлем ачы.*[2]

“Хөсрәү вә Ширин” — сурәтлелек, тел байлыгы, стиль нәфислеге ягыннан искиткеч әсәр. Романда кулланылган образлар, шигъри чаралар, поэтик детальләр, ничектер, табигый агын, сурәтле фикерләү белән органик кушылып тора. Автор хикәяләү һәм тасвирлау, төш күрү, әңгәмә, лирик чигенеш, фәлсәфи уйлану, антитеза һәм башка ысуллардан һәм чаралардан иркен файдалана. Пейзаж нигездә вакыт агышын белдерүгә, геройларның рухи халәтен, үзара мөнәсәбәтләрен ачуга хезмәт итә.

Әсәрнең тәэсир көчен арттыру, укучының зиһенен баету юнәлешендә автор кулланган төрле чаралар арасында традицион образлар да, моңа кадәр бик күзгә ташланмаган сурәтләр дә бар. “Хөсрәү вә Ширин”дәге геройлар, рухи халәтләренә карап, Ягъкуб һәм Йосыф белән чагыштырыла. Мәсәлән, Иранга баргач, Ширинне тау-таш арасына урнаштыралар. Бу урында шагыйрь болай ди: “Йосыф тик казгу козыгынга (коесына) атылмыш”. Фәрһад Шириннең сөйләмен ишетү белән сабырсыз кала. Чөнки кызның сүзе Әфләтун кебек акыл ияләрен дә зиһенсез калдырырлык.

---

[1]Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә / Котб. – Казан : КДУ, 1969. - 411 б.

[2] Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман) / Котб. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 187 б.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. - Яр Чаллы, 1997. - 128 б.
2. Абилов Ш.Ш. Низами һәм татар әдәбияты // Казан утлары. - 1983. - №3.- 166 б.
3. Алиев Г.Ю. Темы и сюжеты Низами в литературах народов Востока / Г.Ю. Алиев. – Москва: Наука, 1985. –332 с.
4. Амирханов Р.М. От Кутба до Сайфа Сараи / Амирханов Р.М // Татарская социально-философская мысль средневековья. – Казань: Таткнигосиздат, 1993. – 60 с.
5. Амирханов Р.М. Союз разума и любви в этнической концепции Кутба. / Амирханов Р.М // Татарская социально-философская мысль средневековья. – Казань: Таткнигосиздат, 1993. – 60 с.
6. Амирханов Р.М. “Философия любви” в “Хосров-Ширин хикаяты” / Амирханов Р.М. // Татарская социально-философская мысль средневековья. – Казань: Таткнигосиздат, 1993. – 60 с.
7. Ахметьянов Р.Г. Музыкальные термины в поэме “Хусрав и Ширин” Кутба и их отношение к поволжскому тюрки / Р.Г. Ахметьянов // Страницы истории татарской музыкальной культуры. – Казань: 1991. – 115 с.
8. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма) / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995.– 93 б.
9. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге / Г.Х.Әхәтов. - Казань: Татар.кит.нәшр., 1980.- 177 б.
10. Әхәтов Г.Х. Татар телендә фразеологик әйтелмәләр: Автореф. дис. канд. филол. наук / Г.Х.Әхәтов. – Казан, 1954. – 26 б.

11. Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Котб кай як кешесе? / М. Әхмәтҗанов // Идел. - 1997. - №12. – 43 б.
12. Әхмәтъянов Р. “Хөсрәү вә Ширин” / Р. Әхмәтъянов // Мирас. – 1992. - №2. – 22 б.
13. Әхмәтова Э. Низами һәм Котб иҗатына бер караш / Э. Әхмәтова // Татарстан. - 1996. - №4.
14. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. Беренче том / Н. Исәнбәт. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 495 б.
15. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. Икенче том / Н. Исәнбәт. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 365 б.
16. Копыленко М.Н., Попова З.Д. Очерки по общей фразеологии. - Воронеж: Изд-во ВГУ, 1972. – 144 с.
17. Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә / Котб. – Казан : КДУ, 1969. - 441 б.
18. Котб. Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман) / Котб. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 278 б.
19. Миңнегулов Х. Котб иҗаты / Х. Миңнегулов. – Казан: КДУ, 1976. - 79 б.
20. Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. (Вопросы взаимосвязей и поэтики) / Х. Миннегулов. – Казань: Изд-во КГУ, 1993. – 384 с.
21. Наджип Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV в.: На материале “Хосрау и Ширин” Кутба / Э.Н. Наджип. – Москва: Наука, 1979. – 262 с.
22. Наджип Э.Н. О диалектном составе языка Кутба. (Вопросы диалектологии тюркских языков) / Э.Н. Наджип. – Баку, 1960. – 86 с.
23. Наджип Э.Н. “Хосрау и Ширин” Кутба и его язык: Тюркологический сборник / Э.Н. Наджип. – Москва: Наука, 1966. – 302 с.
24. Сафин М. Мир этот жив любовью / М. Сафин // Аргамак. – 1998. - №3. – 110 с.

25. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.
26. Таһирҗанов Г.Т. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәре / Г.Т. Таһирҗанов // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.1. - Казан:Татар.кит.нәшр., 1984. – 432 б.
27. Фазылов Э. О словаре “Хосров и Ширин” Котба / Э. Фазылов // Тюркская лексикология и лексикография. – Москва: Наука, 1971. – 310 с.
28. Хаков В.Х. Татар әдәби теле: Стилистика. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. - 304 б.
29. Хисамов Н. XIV йөз шигъриятендә кеше идеалы / Н. Хисамов // Казан утлары - 1978. - №3.
30. Юсупов Р. А. Тәрҗемә һәм тел культурасы. - Казан: Татар.кит.нәшр. - 1973. - 128 б.
31. Зайончковкий А. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасы (транскрипция). - Warszawa: Panstwowe wydawnictwo naukowe, 1958. — I. — Tekst, 304 + XI S.